ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.05.2021 г. Заинск № 322

**«Мәгариф оешмаларын Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының анык территорияләренә беркетү турында» 2021 елның 15 мартындагы 155 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

«Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча балалрны укуга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 02 сентябрендәге 458 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы боерыгын үтәү йөзеннән, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

## карар бирә:

1. «Мәгариф оешмаларын Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының анык территорияләренә беркетү турында» 2021 елның 15 мартындагы 155 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Мәгариф оешмаларын Зәй муниципаль районының анык территорияләренә һәм торак пунктларына беркетүне (1, 2 кушымталар) расларга;
1.2. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен Зәй муниципаль районының анык территорияләренә һәм торак пунктларына беркетүне (баланың ата-анасының (законлы вәкиленең) теләген исәпкә алып) расларга (3 нче кушымта)».
1.3. 1 нче кушымтаның һәм 2 нче кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Мәгариф оешмаларын Зәй муниципаль районының анык территорияләренә һәм торак пунктларына беркетү»;
1.4. 3 нче кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен Зәй муниципаль районының анык

территорияләренә һәм торак пунктларына беркетү (баланың ата-анасының (законлы вәкиленең) теләген исәпкә алып)».

2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Л.Р. Печина
3-27-42